**ТР Аксубай муниципаль районы**
**Иске Илдерәк авыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАР**

№ 4 31.03.2015ел

"Авыл җирлеге территорияләрен санитар
чистарту буенча икеайлык үткәрү турында"

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.03.2015 ел, №430-р боерыгын, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 23.03.2015 ел, №35 боерыгын үтәп һәм Иске Илдерәк авыл җирлеге Уставына таянып. Торак пункт территорияләрен санитар чистартуны тизләтү һәм торак пункт территорияләрен Иске Илдерәк авыл җирлеге халкының санитар-эпидемиологик һәм экологик иминлегенә җавап бирүче хәлгә китерү максатларында Иске Илдерәк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. 2015 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр торак пункт территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык игълан ителергә тиеш.
2. 1 нче кушымта нигезендә торак пункт территориясен санитар чистартуны үткәрү буенча эшләрне координацияләү өчен оператив штаб булдырырга.
3. Торак пунктлар старосталарына предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм башка оешмаларга һәм халыкка икеайлык үткәрү турында мәгълүмат җиткерергә тәкъдим итәргә.
4. Комиссия әгъзаларына торак пункт старосталары белән берлектә санитар-экологик хәлне яхшыртуга, шул исәптән агачлар һәм куаклар утыртуга, зиратларны, паркларны төзекләндерүгә, чүп өчен контейнерлар әзерләүгә һәм ремонтлауга, 2 нче кушымта нигезендә каты көнкүреш калдыклары полигонына чүп чыгару буенча конкрет чаралар үткәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubayevo.tatarstan.ru
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Илдерәк авыл җирлеге
Башлыгы В.К. Альметкин

Кушымта №1
Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге
Башкарма комитет карарына
31.03.2015ел № 4

**Иске Илдерәк авыл җирлеге торак пунктларының эшләрен координацияләү, санитар чистарту буенча оператив штаб составы.**

1. Альметкин В.К. - **штаб начальнигы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе.**
2. Енизеркина В.В. - **штаб начальнигы урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.**
3. Купцов В.В. штаб начальнигы ярдәмчесе, Яңа Илдерәк авылы старостасы.

Штаб әгъзалары:

4. Маклаков Н.А. – Иске Илдерәк авылы СДК операторы.
5. Сашина И.М. - җирлекнең бухгалтерлык хисабы буенча баш белгече.
6. Карпов В.П. - Тарханка авылы старостасы

Кушымта №2
Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге
Башкарма комитет карарына
31.03.2015ел №4



**Иске Илдерәк авыл җирлеге торак пунктлары территориясен санитар-экологик чистарту буенча чаралар планы.**

| № | Эчтәлек | Башкару вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| | Йортлар янында санитар тәртип урнаштыруны таләп итеп авыл гражданнарын ишегалдында урап узу | 01.04.2015 ел - 05.04.2015 ел | Торак пунктларда чисталык һәм тәртип урнаштыру буенча Комиссия |
| | Торак йортлар, җәмәгать бинаалары янында тәртип урнаштыру. | 05 .04.2015 ел - 08.05.2015 ел | Торак пунктларда чисталык һәм тәртип урнаштыру буенча Комиссия һәм учреждение җитәкчеләре |
| | Урамнар һәм торак булмаган йортлар янында тәртип урнаштыру | 10.04.2015 ел - 15.05.2015 ел. | Башкарма комитет җитәкчесе һәм участок инспекторы |
| | Баганаларны һәм агачларны һәм йорт фасадларын агарту | 25.04.2015 ел. -08.05.2015 ел | авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| | Зиратларны җыештыру һәм койманы ремонтлау | 25.04.2015 ел- 08.05.2015ел | авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| | Агач утырту | График буенча | авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| | Каты көнкүреш калдыкларын чыгару | график буенча | авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| | Терлекләр каберлегенн ремонтлау | График буенча | авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| | Бөек Ватан сугышы һәйкәлләрен ремонтлау | 8.05.2015 ел кадәр | авыл җирлегенең башкарма комитеты |